# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасының 1994 елга
бюджет системасы турында

"Татарстан Республикасында бюджет төзелеше һәм бюджет гамәлләре турында" Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1 статья. Президент тарафыннан тәкъдим ителгән 1994 елга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджет проектын исәпкә алырга.

2 статья. Татарстан Республикасының 1994 елга республика бюджетының керемнәре әсталгән бәяләргә салым, акцизлар, халык хуҗалыгының мөһим тармакларын финанслау өчен махсус салым, табышка салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше һәм башка керемнәр исәбенә барлыкка килә дип билгеләргә.

3 статья. Татарстан Республикасының 1994 елга республика бюджетында керемнәрнең килере суммасы 1823125 млн.сум икәнен исәпкә алырга, шул исәптән түбәндәге төп чыганаклар буенча:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Өстәлгән бәяләргә салым | - 361500 |
| Акцизлар | - 259100 |
| Нефть буенча акцизлар | - 442000 |
| Табышка салым | - 232272 |
| Физик затлардан керемнәргә салым | - 46391 |
| Хосусыйлаштырудан керемнәр | - 16000 |
| Мөлкәткә салым | - 9725 |
| Җир асты байлыклары өчен түләүләр | - 61095 |
| Җир өчен түләүләр | - 9300 |
| Башка төрле салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр | - 51408 |
| Халык хуҗалыгының мөһим тармакларын финанслау өчен махсус салым | - 139000 |
| Түбәнге бюджетлардан керә торган акчалар | - 195334 |

4 статья. Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче табышка салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең хокукый затлары өчен - 22 процент күләмендә;

б) банклар һәм иминлек оешмалары өчен - 30 процент күләмендә;

в) арадашчы гамәлләре һәм килешүләре буенча биржалар, брокер конторалары һәм предприятиеләр өчен - 32 процент күләмендә.

5 статья. 1994 елның 1 апреленнән түбәндәгеләрне кертергә:

а) мәгариф учреждениеләренең ихтыяҗлары өчен предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның (бюджетныкылардан гайре) хезмәт өчен түләү фондларыннан 1 процент күләмендә алынучы җыем.

Предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның әлеге җыемны түләү буенча чыгымнары предприятиеләр эшчәнлегенең финанс нәтиҗәләренә кертелә;

б) торак фондын һәм җәмгыяви-көнкүреш өлкәсе объектларын тоту өчен предприятиеләр саткан продукция күләменнән 1,5 процент рәвешендәге салым.

6 статья. Су хуҗалыгы системаларыннан сәнәгать предприятиеләре үзләренә ала торган су өчен 1994 елның 1 гыйнварена гамәлдә булган түләү 1994 елда 4,7 коэффициенты белән алына дип билгеләргә.

7 статья. Предприятиеләрнең мөлкәтенә салым буенча ставкаларны 1994 елда салым салу базасының 1 проценты күләмендә билгеләргә.

8 статья. 1994 елда казылма байлыкларны чыгарган өчен түләүләрнең ставкаларын чыгарылган байлыкны сату бәяләреннән (өстәлгән бәяләргә салымнардан һәм акцизлардан гайре) түбәндәге процентларда билгеләргә:

| Казылма байлыкларның (чималның) төрләре | Ставка |
|---|---|
| 1. Нефть һәм газ | 6 |
| 2. Табигый битум | 4 |
| 3. Гипс ташы | 4 |
| 4. Фосфоритлар | 4 |
| 5. Цемент чималы | 4 |
| 6. Туфракны известьлау өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. Карбонат токымнары | 3 |
| 8. Киселгән таш | 3 |
| 9. Бут һәм вак таш өчен төзелеш ташы | 3 |
| 10. Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. Пыяла һәм форма комы | 4 |
| 12. Төзелеш комы | 3 |
| 13. Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. Кирпеч балчыклары | 2,5 |
| 16. Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. Җир асты сулары | 6 |

<u>9 статья.</u> 1994 елда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр бюджет дәрәҗәләре буенча түбәндәгечә бүленә (%):

402



| Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
|---|---|---|
| | республика | районнар (шәһәрләр) |
| 1. Казылма байлыкларны чыгарган өчен түләүләр | | |
| - торф, сапропель, җир асты сулары һәм шифалы сулар буенча; | - | 100 |
| - кин таралган казылма байлыклар буенча; | - | 100 |
| - нефть, газ, ком, Идел һәм Кама елгалары үзәненнән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум, гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| - казылма байлыкларның башка төрләре буенча (фосфоритлар, бентонит балчыклары, керамзит балчыклары, төзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгән таш, пыяла һәм форма комы, глауконитлар, цеолитлар); | - | 100 |

| | | |
|---|---|---|
| 2. Кагылма байлыкларны лицензияләрдә билгеләнгән лимитлардан (квоталардан) артыграк кулланган өчен түләүләр 5 мәртәбәгә арттырылган ставка буенча алына; - нормативлардан артыграк кулланылыш билгеләгән орган хисабына - 10% | 60 | 30 |
| 3. Кагылма байлыкларны чыгару белән бәйле булмаган җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр | 50 | 50 |

10 статья. 1994 елда районнарның һәм шәһәрләрнең бюджетларына түбәндәгеләрне тапшырырга:

- предприятиеләрнең, берләшмәләрнең һәм оешмаларның салым салынучы табышларыннан 25 процент күләмендәге табышка салым, боларга түбәндәгеләр керми: Әлмәт шәһәре - 8%, Чаллы шәһәре - 15%, Түбән Кама шәһәре - 8%, Азнакай районы - 9%, Әлмәт районы - 3%, Бөгелмә районы - 14%, Сарман районы - 8%, Бөгелмә шәһәре - 9%, Тукай районы - 10%, Лениногорск шәһәре - 21%;

- физик затлардан керем салымы 11% ставка буенча, боларга түбәндәгеләр керми: Әлмәт районы - 10%, Түбән Кама шәһәре - 60%, Азнакай районы - 59%, Тукай районы - 40%, Әлмәт шәһәре - 37%, Чаллы шәһәре - 50%, Бөгелмә шәһәре - 80%, Лениногорск ше-

һәре - 95% - әлеге территорияләрнең бюджетларына 11%лы ставка буенча керүче салым төрләреннән исәпләнә;

- предприятиеләрнең мөлкәтенә салым тулысынча.

11 статья. Татарстан Республикасының 1994 елга республика бюджетыннан агымдагы чыгымнар буенча ассигнованиеләр күләменең иң югары чиген - 1735291 млн.сум, ә бюджет үсеше буенча 512558 млн.сум күләмендә расларга.

12 статья. Татарстан Республикасының 1994 елга республика бюджетыннан ассигнованиеләрне 2247849 млн.сум күләмендә түбәндәге максатларга юнәлтергә:

(млн.сумнарда)

| | Барысы | Шул исәптән: агымдагы чыгымнар бюджеты | Шул исәптән: үсеш бюджеты |
|---|---|---|---|
| Халык хуҗалыгын финанслауга, | 1003268 | 799435 | 203833 |
| шулардан: | | | |
| - агросәнәгать комплексына | 309901 | 181901 | 128000 |
| - ягулык сәнәгатенә | 1700 | 1700 | - |
| -торак-коммуналь хуҗалыгына | 19150 | 2000 | 17150 |
| - сәламәтлек саклауның ху- | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| җалык органнарына | 13720 | 13720 | - |
| - дәүләт кино фондына | 3540 | 3540 | - |
| - проект эшләренә | 90 | - | 90 |
| - ветеринария идарәләренә | 24184 | 16384 | 7800 |
| - Татавтотранска | 75000 | 75000 | - |
| - Татгазга | 17400 | 17400 | - |
| - көйләүле бәяләр буена сатыла торган продукциягә дотация | 75000 | 75000 | - |
| - Горький тимер юлының Казан бүлегенә | 13500 | 13500 | - |
| - "Татарстан һава юллары"-ның Казан авиация предприятиесенә | 3000 | 3000 | - |
| - Казан елга портына | 5400 | 5400 | - |
| - Чаллы елга портына | 600 | 600 | - |
| - тапшырылган терлек продукциясенә дотация | 245000 | 245000 | - |
| - җир өчен түләүләр хисабыннан чыгымнарга | 9300 | - | 9300 |
| - Урман хуҗалыгы министрлыгына | 38000 | 29700 | 8300 |
| - ТТК өчен торак йортлар төзелешенең бәясе үсешен компенсацияләүгә | 6450 | - | 6450 |
| - табигатьне саклау буенча гамәлләргә | 7183 | 440 | 6743 |
| - ведомстволардагы торак фондын тотуга | 115150 | 115150 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| - оборона предприятиеләренә (конверсия) | 200000 | - | 200000 |
| Җәмгыяви өлкәне финанслауга, | 288089 | 262459 | 25630 |
| шулардан: | | | |
| - халык мәгарифенә | 72115 | 61715 | 10400 |
| - мәдәниятка | 20208 | 19008 | 1200 |
| - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга, мәгълүмат агентлыгына | 4017 | 4017 | - |
| - телевидение һәм радиога | 3042 | 3042 | - |
| - сәламәтлек саклауга | 152626 | 140416 | 12210 |
| - санэпид күзәтүгә | 16000 | 15000 | 1000 |
| - физик тәрбиягә һәм спортка | 1300 | 1300 | - |
| - җәмгыяви тәэминатка | 12586 | 11766 | 820 |
| - фәнгә | 4695 | 4695 | - |
| - яшьләр сәясәте өлкәсендәге гамәлләрне финанслауга | 1500 | 1500 | - |
| Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарын тотуга | 42994 | 42994 | - |
| Балаларга пособиеләр һәм компенсацияләр түләүгә | 120000 | 120000 | - |
| Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фондына | 4233 | 4233 | - |
| Төрле түләүләр һәм башка чыгымнарга | 59586 | 57586 | 2000 |
| Капитал салулар, шул исәптән Татарстан Респуб- | 281095 | - | 281095 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ликасының АлАЗ төзелешен- | | | |
| дә катнашу өлешенә - 30000; - | - | - | - |
| Татарстан Республикасы | | | |
| Югары Советының кунакха- | | | |
| нә тибындагы йортын | | | |
| төзүгә - 1500 | | | |
| Җирле бюджетларга тапшыры- | | | |
| ла торган дотацияләргә | 448584 | 448584 | - |

13 статья. Дәүләт хакимияте һәм дәүләт идарәсе органнарын тотуга чыгымнарны 42994 млн.сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(млн.сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Югары Советын, аның Президиумын, Татарстан Республикасы Югары Советы Секретариатын тотуга | 3232 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларына депутатлык вәкаләтләрен үтәү белән бәйле чыгымнарны каплауга | 48 |
| Татарстан Республикасы Югары Советы сессияләрен уздыру белән бәйле чыгымнар | 130 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Президенты һәм вице-президенты, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы консультатив органнар, Президент аппараты эшчәнлеген финанслау буенча чыгымнар | 2137 |
| Конституция күзәтүе комитетын тотуга | 73 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт (парламент) тикшерүе комитетын тотуга | 549 |
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетын тотуга | 3150 |
| Татарстан Республикасы министрлыкларын, ведомстволарын һәм аларның органнарын тотуга | 31302 |
| Татарстан Республикасының даими вәкилиятләрен тотуга | 1500 |
| Татарстан Республикасы Югары арбитраж судын тотуга | 873 |

14 статья. 1994 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетларына халыкның җәмгыяви дәрәҗәсен тигезләү өчен дотацияләр, шулай ук гамәлдәге бә-

ялəр системасы шартларында төбəклəр арасында керемнəрнең тигез бүленмəвенə бəйле компенсациялəр түлəүгə 448584 млн.сум күлəмендə акча бүленə, шул исəптəн:

| | (млн.сумнарда) |
|---|---|
| Аксубай | 9136 |
| Актаныш | 11448 |
| Алексеевск | 7620 |
| Апас | 8298 |
| Алабуга | 6189 |
| Арча | 10212 |
| Балтач | 10659 |
| Баулы | 1532 |
| Буа | 13545 |
| Балык Бистəсе | 10187 |
| Биектау | 7469 |
| Зеленодол | 5476 |
| Кама Тамагы | 6243 |
| Кукмара | 9511 |
| Кайбыч | 5799 |
| Лаеш | 5293 |
| Лениногорск | 6443 |
| Мамадыш | 13640 |
| Менделеевск | 432 |
| Минзəлə | 4407 |
| Мөслим | 8228 |
| Октябрь | 8083 |
| Питрəч | 7299 |

| | |
|---|---|
| Саба | 8659 |
| Спас | 9742 |
| Тәтеш | 11538 |
| Теләче | 5363 |
| Түбән Кама | 4372 |
| Чирмешән | 5317 |
| Чистай | 4801 |
| Чүпрәле | 8686 |
| Ютазы | 1187 |
| Югары Ослан | 7345 |
| Яңа Чишмә | 5509 |
| Әтнә | 4869 |
| Әгерҗе | 8256 |
| Әлки | 8935 |
| Азнакай шәһәре | 7744 |
| Алабуга шәһәре | 9396 |
| Зеленодол шәһәре | 8796 |
| Чистай шәһәре | 4015 |
| Казан шәһәре | 146905 |

15 статья. Татарстан Республикасының 1994 елга республика бюджеты нисбәтләнмәвенең чиген анык фаразланган керемнәренең 24% ы күләмендә билгеләргә.

16 статья. Татарстан Республикасының республика бюджеты кассасындагы акча әйләнешен 1995 елның 1 гыйнварена 8 млрд.сум күләмендә расларга.

17 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм

Милли банкы 1994 елда хисап системасын оештыруны һәм аның нәтиҗәле эшчәнлеген, Татарстан Республикасының республика һәм җирле бюджетларының чыгымнары һәм керемнәре үтәлешен тәэмин итәргә тиеш. Бюджетларның касса үтәлеше гамәлләре, комиссия түләүләре алынмыйча, Милли банк тарафыннан һәм аның кушуы буенча башка банклар тарафыннан да башкарыла дип билгеләргә.

18 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына кирәк очракларда өстәлгән бәяләргә салым һәм табышка салым буенча ташламалар бирүне рөхсәт итәргә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 1994 елда, хосусыйлаштырылган предприятиеләрнең кыйммәтле кәгазьләрен дә кертеп, хөкүмәтнең кыйммәтле кәгазьләрен чыгаруны һәм беренчел урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре, Кремль,
1994 елның 21 апреле
N 2106-XII